КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 1 октябрь г.Казань № 845

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программалары һәм өстәмә гомуми үстерү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге торган бүлекчәсе булган югары белем бирү мәгариф оешмасына ярдәм күрсәтү» гранты һәм аны бирү тәртибе турында» 2021 ел, 13 август, 721 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программалары һәм өстәмә гомуми үстерү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге торган бүлекчәсе булган югары белем бирү мәгариф оешмасына ярдәм күрсәтү» гранты һәм аны бирү тәртибе турында» 2021 ел, 13 август, 721 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 6 март, 213 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә

алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы» сүзләрен «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программалары һәм өстәмә гомуми үстерү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге торган бүлекчәсе булган югары белем бирү мәгариф оешмасына ярдәм күрсәтү» гранты һәм аны бирү тәртибе турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 13 август, 721 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 1 октябрь, 845 нче карары редакциясендә)

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программалары һәм өстәмә гомуми үстерү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге торган бүлекчәсе булган югары белем бирү мәгариф оешмасына ярдәм күрсәтү» гранты һәм аны бирү тәртибе турында
нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең ««Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программалары һәм өстәмә гомуми үстерү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге торган бүлекчәсе булган югары белем бирү мәгариф оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия формасында грант (алга таба – грант) бирү механизмын, максатын һәм шартларын билгели.

2. Грант бирү максаты – Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программалары һәм өстәмә гомуми үстерү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге торган бүлекчәсе булган, бюджет учреждениесе яки автоном учреждение булып торган югары белем бирү мәгариф оешмасында аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларга комплекслы ярдәм күрсәтү системасын булдыру проектын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.

3. Әлеге Нигезләмәдә аннан файдалану максатлары өчен түбәндәге терминнар кулланыла:

грант алырга теләүче – Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып барган һәм Татарстан Республикасы бюджетына салым түләгән, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программалары һәм өстәмә гомуми үстерү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге торган бүлекчәсе булган, бюджет учреждениесе яки автоном учреждение булып торган, сайлап алуда катнашуга заявка (алга таба – заявка) биргән югары белем бирү мәгариф оешмасы;

грант алучы – сайлап алу йомгаклары буенча грант бирү турында карар кабул ителгән грант алырга теләүче.

4. Грант аны алучыга әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында билгеләнгән максат өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) булып торган бюджет акчасы белән баш эш итүчегә тиешле финанс елына билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

Грантның күләме 24 383,4 мең сум күләмендә тәшкил итә. Ел саен бер грант бирелә.

Грант турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

5. Сайлап алуны үткәрү ысулы – грант бирү нәтиҗәләренә ирешүнең иң яхшы шартларыннан чыгып, сайлап алуда җиңүчене билгеләүдән торган конкурс.

6. Заявкаларны бәяләү критерийлары:

штат расписаниесендә аутистик спектры бозылган балалар белән эшләү буенча белгечләр булу;

аутистик спектры бозылган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүне гамәлгә ашыру өчен методик шартлар булу;

аутистик спектры бозылган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүне гамәлгә ашыру өчен матди-техник шартлар булу;

мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган бүлекчә турында нигезләмә булу;

аутистик спектры бозылган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программасы булу;

грант алырга теләүченең мәктәпкәчә белем бирү буенча җайлаштырылган мәгариф программасында тәкъдим ителгән әлеге юнәлеш буенча эш формаларының, аутистик спектры бозылган балаларны укыту методикаларының һәм технологияләренең төрлелеге һәм оригинальлеге.

7. Заявка бирү көненә кадәр 30 календарь көн калган датага карата грант алырга теләүче түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

грант алырга теләүче чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган, Россия Федерациясендә активларга

арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

грант алырга теләүче экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

грант алырга теләүче БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

грант алырга теләүче әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән максат өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый;

грант алырга теләүче «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

грант алырга теләүченең бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы булмый яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

грант алырга теләүченең башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмый (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

грант алырга теләүче үзгәртеп оештыру (грант алырга теләүчегә башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмый, аңа карата банкротлык процессы билгеләнми, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмый;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки грант алырга теләүченең баш бухгалтеры турында мәгълүматлар

булмый.

8. Сайлап алуда катнашу өчен грант алырга теләүче вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

шул исәптән әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында күрсәтелгән форма буенча грант алырга теләүче турында, грант алырга теләүче тарафыннан бирелә торган заявка турында мәгълүматны, сайлап алуга бәйле грант алырга теләүче турында башка мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыкны үз эченә алган заявка;

грант алырга теләүченең гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга кертелә торган барлык үзгәрешләр турында документлар күчермәләре;

грант алырга теләүчегә карата гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органының (дәүләт органының) сайлап алуда грант алучы катнашуга ризалыгы;

грант алырга теләүчене дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе яисә Юридик затларның бердәм дәүләт реестры язуы битләре күчермәсе;

җитәкче яки грант алырга теләүче исеменнән эш итәргә вәкаләтле зат һәм грант алырга теләүченең баш бухгалтеры тарафыннан имзаланган, грант алырга теләүченең әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган мәгълүмати белешмә кәгазе;

бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре түләү бурычы булмавын яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмавын раслый торган салым органының белешмә кәгазе;

мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программалары буенча эшчәнлек башкаруга лицензия күчермәсе;

грант алырга теләүченең штат расписаниесе;

аутистик спектры бозылган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программасы;

мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган грант алырга теләүче бүлекчәсе турында нигезләмә;

аутистик спектры бозылган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүне гамәлгә ашыру өчен матди-техник тәэминат исемлеге;

мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программасы гамәлгә ашырыла торган бүлмәләр барлыгын һәм алардан файдалану хокукын раслый торган документлар;

грант алырга теләүче тарафыннан эшләнгән аутистик спектры бозылган балаларны укыту методикалары һәм технологияләре.

Әгәр грант алырга теләүче тарафыннан әлеге пунктның бишенче һәм җиденче абзацларында каралган документлар тапшырылмаган булса, вәкаләтле орган аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә ала.

Грант алырга теләүче сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән срокларда заявка булдыра һәм бирә. Заявкага грант алырга теләүченең җитәчесе үз кулын куя һәм ул вәкаләтле органга турыдан-туры яисә почта аша җибәрелә.

Грант алырга теләүче тарафыннан заявка бирү датасы итеп вәкаләтле органның урнашу урыны буенча почта бүлегенә заявка керү датасы яки турыдан-туры вәкаләтле

органга заявка керү датасы санала.

Электрон формада файдалану мөмкинлеге булган, заявкага кертелә торган документлар һәм материаллар күчермәсендә мәгълүматны карау өчен билгеләнгән һәркем файдалана алырлык программа тәэминаты белән документны тулысынча яки аның бер өлешен карау мөмкинлеге тәэмин ителә торган, киң таралган ачык форматта булырга тиеш (кәгазь чыганакта урнаштыру чыганагына гиперсылтама күрсәтелә яисә электрон файл җайланмасы теркәлә) һәм шифрланмаган яисә махсус программа яисә технологик чаралардан башка аларның эчтәлеге белән танышуны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән сакланмаган булырга тиеш.

Грант алырга теләүче заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булганда грант алырга теләүче заявкалар бирү өчен билгеләнгән вакыт эчендә кабат заявка бирергә хокуклы.

Заявкага үзгәрешләр кертү яисә заявканы кире алу грант алырга теләүче тарафыннан әлеге Тәртиптә билгеләнгән заявканы төзүнең шундый ук тәртибендә грант алырга теләүче тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9. Сайлап алу вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Заявкаларны сайлап алуны үткәрү сроклары, кабул итү сроклары, заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты вәкаләтле орган боерыгы белән раслана.

Вәкаләтле орган, заявкалар бирә башлау датасына кадәр биш календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуны уздыру турында игълан урнаштыруны тәэмин итә, анда түбәндәгеләр турында мәгълүмат күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкалар бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасы һәм вакыты, шул ук вакытта заявкаларны кабул итүнең тәмамлану датасы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган биш календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

вәкаләтле органның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Нигезләмәнең 16 пункты нигезендә грант бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт мәгълүмат системасының сайлап алуны уздыруны тәэмин итә торган битләренең домен исемен һәм (яисә) күрсәткечләрен;

әлеге Нигезләмәнең 10 пункты нигезендә грант алырга теләүчеләргә карата таләпләрне һәм грант алырга теләүче тарафыннан әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкаларны бәяләү критерийларын;

заявкаларны бирү тәртибен һәм әлеге Тәртипнең 8 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, заявкаларга үзгәрешләр кертү тәртибе;

әлеге Тәртипнең 10 – 12 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

заявкаларны эшләп бетерү өчен кире кайтару тәртибе;

заявкаларны кабул итмәү тәртибе, шулай ук аларны кабул итмәү нигезләре;

сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләрен грант алырга теләүчегә аңлату тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан грант бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) тиешле имза кую срогын;

сайлап алуны үткәрүне туктату тәртибе һәм очраклары, сайлап алу йомгаклары буенча килешүләр төзү очраклары һәм сайлап алу үткәрелмәгән дип тану очраклары;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

бердәм порталда һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсен урнаштыру сроклары (ул сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак була алмый).

Вәкаләтле орган, табигый яисә техноген һәлакәтләр, хәрби хәрәкәтләр, вәкаләтле органнар тарафыннан гадәттән тыш дип танылган башка хәлләр белән бәйле рәвештә барлыкка килгән, җиңеп булмый торган вакыйгалар килеп чыккан очракта, сайлап алу уздырмый.

Вәкаләтле орган тарафыннан бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуны уздырмау турында белдерүне урнаштыру заявкалар бирү срогы тәмамланган датага кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә. Сайлап алуны уздырмау турында белдерүгә вәкаләтле орган җитәкчесе тарафыннан кул куела, бердәм порталда һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла һәм сайлап алуны уздырмау сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

Сайлап алу бердәм порталда аны уздырмау турында белдерү урнаштырылган көннән сайлап алу гамәлдән чыгарылган дип санала.

Әлеге пунктның унсигезенче абзацы нигезендә сайлап алуны юкка чыгару срогы тәмамланганнан соң һәм субсидия алучы белән килешү төзелгәнче вәкаләтле орган Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә җиңеп булмый торган көч шартлары барлыкка килгән очракта гына сайлап алуны юкка чыгарырга мөмкин.

10. Вәкаләтле органга кергән заявка керү датасына һәм вакытына карап чират буенча кергән көннән алып бер эш көне эчендә теркәлә. Заявка биргән грант алырга теләүченең вәкаләтле вәкиленә, аны алу датасын һәм вакытын күрсәтеп, заявка алган Вәкаләтле органның вазыйфаи заты имзасы белән заявка алуда расписка бирелә.

Заявка почта элемтәсе оешмасы аша кергәндә, заявканы теркәү датасы итеп вәкаләтле органга почта әйберләрен турыдан-туры тапшыруны гамәлгә ашыручы почта элемтәсе оешмасының структур бүлекчәсе тарафыннан вәкаләтле орган адресына килгән, почта әйберенә почта элемтәсе оешмасының тиешле структур бүлекчәсе штемпеле сугылган почта әйберен алу датасы һәм вакыты санала.

Заявкалар вәкаләтле органның урнашу урыны адресы буенча карала. Бер грант алырга теләүче бер генә заявка бирергә мөмкин.

11. Заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү максатларында вәкаләтле орган тарафыннан заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү буенча конкурс комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә. Комиссия вәкаләтле зат хезмәткәрләре арасыннан составы

кимендә биш әгъзадан (рәисне кертеп) торган итеп төзелә.

Комиссия эше утырышларда башкарыла. Әгәр утырышта комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, комиссия утырышы тулы хокуклы дип санала.

Комиссия заявкаларны кабул итү срогы чыккан көннән соң килә торган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча:

заявкаларны кергән чираты нигезендә, шулай ук грант алырга теләүченең әлеге Тәртипнең 6 һәм 7 пунктларында билгеләнгән сайлап алу критерийларына һәм таләпләренә туры килү-килмәвен карап тикшерә;

сайлап алуда җиңүчене билгеләү турында карар кабул итә, ул Комиссия утырышы үткәрелгән көндә беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм аңа Комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан имза куела.

Комиссия заявкаларны ачуны һәм аларны әлеге Нигезләмәнең 6 һәм 7 пунктларында билгеләнгән бәяләү критерийларына һәм таләпләргә туры килүен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Әгәр ул сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм заявканы кире кагу өчен нигезләр булмаганда, заявка дөрес дип таныла. Заявканың сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килүе хакында карар грант алырга теләүчеләр тарафыннан заявка составында бирелгән мәгълүматны һәм документларны тикшерү нәтиҗәләрен алу датасына карата Комиссия тарафыннан Комиссия рәисе кул куя торган заявкаларны карап тикшерү беркетмәсе формасында кабул ителә. Заявкаларны карап тикшерү беркетмәсе бердәм порталда аңа кул куелган көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

Комиссия карарлары Комиссия утырышында катнашучы әгъзаларның күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәиснең тавышы хәлиткеч булып тора.

Сайлап алуда җиңүчене билгеләү Комиссия тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы нигезендә заявкаларны бәяләү күрсәткечләре буенча тиешле дип танылган заявкаларны бәяләү йомгаклары буенча гамәлгә ашырыла. Комиссия карары сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Заявкаларны бәяләү йомгаклары буенча заявкаларның рангларга бүленгән исемлегендә беренче урынны алган грант алырга теләүче сайлап алуда җиңүче дип таныла.

Баллар тигез булган очракта, вәкаләтле органга заявкасы алданрак кергән грант алырга теләүче сайлап алуда җиңүче итеп дип таныла.

Комиссиянең сайлап алуга йомгаклары ясау беркетмәсе аңа имза куелган көнне вәкаләтле органга җибәрелә.

Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен түбәндәгеләр нигез була:

грант алырга теләүченең әлеге Нигезләмәнең 7 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

грант алырга теләүче тарафыннан бирелгән заявканың һәм (яки) документларның сайлап алу турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүне раслау максатларында грант алырга теләүче тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

грант алырга теләүче тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе.

Карап тикшерү стадиясендә заявка кире кагылган очракта, вәкаләтле орган заявкаларны бирү срогы тәмамланганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә грант алырга теләүчегә заявканы кире кагу турында хәбәр җибәрә.

12. Вәкаләтле орган Комиссиянең сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе нигезендә грант бирү турында яисә грант бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм аны вәкаләтле орган боерыгы белән Комиссиянең сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә кул куелган датадан өч календарь көннән дә соңга калмыйча раслый.

Грант бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

грант алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 7, 8 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

грант алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.

13. Вәкаләтле орган, грант бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган икенче эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәгеләрне үз эченә ала торган сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсен урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкаларын бәяләү датасы, вакыты һәм урыны;

заявканың теркәлү номерын, заявканың керү датасын һәм вакытын, грант алырга теләүченең тулы исемен, грант алырга теләүченең юридик зат адресын, грант алырга теләүче тарафыннан сорала торган грант күләмен күрсәтеп, кергән һәм карап тикшерелгән заявкалар саны;

заявкалары тиешле дип танылган һәм карап тикшерелгән грант алырга теләүчеләр турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән грант алырга теләүчеләр турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

заявкаларны бәяләү эзлеклелеге, заявкаларны бәяләүнең күздә тотылган һәр критерие буенча заявкаларга бирелгән күрсәткечләр, заявкаларны бәяләү нәтиҗәләре нигезендә мондый заявкаларга тәртип саннарын бирү турында кабул ителгән карар;

килешү төзелә торган грантя алучының исеме һәм аңа бирелә торган грантның күләме.

14. Сайлап алу йомгаклары буенча ел саен грант бер грант алучыга бирелә.

15. Грант аны алучының чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә бирелә.

Финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнар юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларга комплекслы булышлык күрсәтү системасын булдыру проектын гамәлгә ашыруга бәйле хезмәткәрләрнең, шул исәптән аутистик спектры бозылган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыруда катнашучы хезмәткәрләрнең, аутистик спектры бозылган балаларны караштырып торуны һәм карауны гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү һәм хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр;

аутистик спектры бозылган балаларны тәрбияләүче гаиләләргә консультация-диагностика ярдәме күрсәтү үзәгенең аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларга комплекслы булышлык күрсәтү системасын булдыру проектын гамәлгә ашыруга бәйле хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү һәм хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр;

аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларга комплекслы булышлык күрсәтү системасын булдыру проектын гамәлгә ашыру башкарыла торган бинаны карап тоту;

аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларга комплекслы булышлык күрсәтү системасын булдыру проектын гамәлгә ашыру өчен кирәкле уеннар, уенчыклар, уку ярдәмлекләре сатып алу.

16. Грант бирү нәтиҗәләре:

грант бирелә торган елдан соң килә торган уку елының 30 маена кадәр срок белән грант алучыда көн саен 5,5 сәгать дәвамында даими нигездә эшли торган кыска вакытлы була торган 10 төркемдә уку елы дәвамында даими булучы аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге кимендә 50 баланы (кыска вакытлы була торган һәр төркемдә балалар саны кимендә биш кеше тәшктл итә) укытуны гамәлгә ашыру;

грант бирелә торган елдан соң килә торган уку елының 30 маена кадәр срок белән аутистик спектры бозылган, консультация-диагностика ярдәме даими күрсәтелүче кимендә 70 бала өчен консультацияләр үткәрү.

17. Грант алучыга грант бирү шартлары:

мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программалары буенча эшчәнлек гамәлгә ашыруга лицензия булу;

грант алучының, грант алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата вәкаләтле орган тарафыннан грант бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән грант бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә ризалыгы;

грант алучыга, шулай ук грант алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып

алуны тыю;

килешүдә билгеләнгән күләмдә грант бирү мөмкин булмавына китерә торган, вәкаләтле органга моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү яки яңа шартлар буенча ризалыкка ирешкәндә килешүне өзү турында шарт.

18. Грант бирү өчен нигез – вәкаләтле орган белән грант алучы арасында әлеге Нигезләмәнең 13 пункты нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуга йомгаклар ясау турында беркетмә урнаштырылган көннән соң килә торган биш эш көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасы нигезендә төзелә торган килешү.

Кирәк булганда вәкаләтле орган һәм грант алучы арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар буенча килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзелә.

Килешүгә шулай ук грант алучы тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 17 пунктында күрсәтелгән грант бирү шартларын үтәү турында нигезләмәләр дә кертелә.

Грант алучы кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Грант алучыны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук грант алучы бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, грант алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган йөкләмәләр һәм грантның файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

19. Грант, вәкаләтле орган тарафыннан грант бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә яки кредит оешмасында грант алучы тарафыннан ачылган субсидия алучының исәп-хисап яки корреспондентлык счетына күчерелә.

20. Грант алучы квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15енә кадәр, шулай ук грант бирелгән елдан соң килә торган елның 15 октябренә кадәр вәкаләтле органга Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча грант бирү нәтиҗәсенең күрсәткеченә ирешү турында хисап һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

Вәкаләтле орган килешүдә өстәмә хисап бирү срокларын һәм формаларын (кирәк булганда) билгеләргә хокуклы.

21. Вәкаләтле орган әлеге органга керү датасыннан алып бер эш көне эчендә кергән хисапларны теркәүгә ала, хисапларны теркәү датасыннан 15 календарь көн эчендә грант алучы тарафыннан тапшырылган хисапларны тикшерүне гамәлгә ашыра, аның йомгаклары буенча хисапларны кабул итү турында яисә кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм грант алучыга кабул ителгән карар турында аны кабул иткән көннән алып өч эш көне эчендә хәбәр итә.

22. Грант бирелгән елдан соң килә торган елның 1 сентябренә карата файдаланылмый калган грантның калган өлеше грант бирелгән елдан соң килә торган елның 15 октябренә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, вәкаләтле орган тарафыннан әлеге акчага килешүдә билгеләнгән тәртиптә ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очрактан тыш).

Хисап финанс елында файдаланылмый калган акчаны әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга җибәрүгә ихтыяҗ булган очракта, грант алучы, хисап елыннан соң килә торган елның 15 октябреннән дә соңга калмыйча, вәкаләтле органга мондый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Вәкаләтле орган, әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны грант алучыдан алган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, агымдагы финанс елында хисап финанс елында файдаланылмаган грантның калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗ булу яисә булмау турында карар кабул итә.

Вәкаләтле орган тарафыннан агымдагы финанс елында грантның хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗы булу турында карар кабул ителгән очракта, вәкаләтле орган һәм грант алучы арасында мондый карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча килешүгә өстәмә килешү төзелә.

23. Вәкаләтле орган грант алучының грант бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне башкара.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

Вәкаләтле орган килешүдә билгеләнгән грант бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешүне һәм грант бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглауны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглау тәртибендә каралган тәртиптә һәм формалар буенча уздыра.

24. Грант алучы тарафыннан грант бирү шартлары һәм тәртибе бозылган очракта, шул исәптән вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган очракта, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 16 пунктында күрсәтелгән грант бирү нәтиҗәләре күрсәткеченә ирешелмәгән очракта, грант алучы алынган акчаларны вәкаләтле органның язма таләбен алган көннән 30 календарь көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кире кайтара.

25. Әлеге Нигезләмәнең 22 һәм 24 пунктларында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, вәкаләтле орган грант алучының алынган акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарудан баш тарту турындагы хәбәрен алган көннән яки грант алучы алган һәм вәкаләтле органның язма таләбендә күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары нигезендә ирекле рәвештә кире кайтару вакыты чыкканнан соң календарь көннәрдә исәпләнә торган җиде көн

эчендә мәҗбүри тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

26. Грантны нәтиҗәле файдалануны, аны бирү шартлары һәм тәртибе үтәлешен контрольдә тоту вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программалары һәм өстәмә гомуми үстерү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге торган бүлекчәсе булган югары белем бирү мәгариф оешмасына ярдәм күрсәтү» гранты һәм аны бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта

Форма

Теркәү номеры: ____________
Заявканы теркәү датасы: ____________

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программалары һәм өстәмә гомуми үстерү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге торган бүлекчәсе булган югары белем бирү мәгариф оешмасына ярдәм күрсәтү» грантын бирүгә сайлап алуда катнашуга
заявка

| Грант алырга теләүченең исеме | Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Грант алырга теләүченең урнашу урыны, телефоны, электрон адресы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | |

Әлеге заявка белән грант алырга теләүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган программалары һәм өстәмә гомуми үсеш бирүче программалар буенча мәгариф эшчәнлеге тора торган бүлекчәсе булган югары белем бирүче мәгариф

оешмасына ярдәм итү» гранты һәм аны бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 ел, 13 август, 721 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган программалары һәм өстәмә гомуми үсеш бирүче программалар буенча мәгариф эшчәнлеге тора торган бүлекчәсе булган югары белем бирүче мәгариф оешмасына ярдәм итү» гранты һәм аны бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый.

Грант алырга теләүче әлеге гариза белән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә грант алу турында, грант алырга теләүче тарафыннан бирелгән гариза турындагы мәгълүматны, тиешле сайлап алу белән бәйле грант алырга теләүче турында башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын раслый.

Кушымталар: 1.
2.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Заявка бирүче | ______________ | ______________________________ | /__________ |
| | (оешма исеме) | (җитәкченең фамилиясе, инициаллары) | (имза) |

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программалары һәм өстәмә гомуми үстерү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге торган бүлекчәсе булган югары белем бирү мәгариф оешмасына ярдәм күрсәтү» гранты һәм аны бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта

Заявкаларны бәяләү критерийлары буенча
заявкаларны бәяләү күрсәткечләре

| Бәяләү критерийлары | Бәя |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Штат расписаниесендә аутистик спектры бозылган балалар белән эшләү буенча белгечләр булу | штат расписаниесендә аутистик спектры бозылган балалар белән эшләү буенча белгечләр булу – 10 балл;<br>штат расписаниесендә аутистик спектры бозылган балалар белән эшләү буенча белгечләр булмау – 10 балл; |
| Аутистик спектры бозылган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүне гамәлгә ашыру өчен методик шартлар булу | аутистик спектры бозылган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүне гамәлгә ашыру өчен методик шартлар булу – 10 балл;<br>аутистик спектры бозылган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүне гамәлгә ашыру өчен методик шартлар булмау – 0 балл; |
| Аутистик спектры бозылган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүне гамәлгә ашыру өчен матди-техник шартлар булу | санитария-эпидемиология нормалары нигезендә җиһазландырылган бүлмәләр, уеннар, уенчыклар, укыту-методик материаллар булу – 10 балл;<br>санитария-эпидемиология нормалары нигезендә җиһазландырылган бүлмәләр булу, уеннар, уенчыклар, укыту-методик материаллар булмау – 5 балл;<br>санитария-эпидемиология нормалары нигезендә җиһазландырылган бүлмәләр булмау, уеннар, |

| 1 | 2 |
|---|---|
| | уенчыклар, укыту-методик материаллар булу – 2 балл;<br>санитария-эпидемиология нормалары нигезендә җиһазландырылган бүлмәләр, уеннар, уенчыклар, укыту-методик материаллар булмау – 0 балл |
| Мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган бүлекчә турында нигезләмә булу | мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган бүлекчә турында нигезләмә булу – 10 балл;<br>мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган бүлекчә турында нигезләмә булмау – 0 балл |
| Аутистик спектры бозылган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программасы булу | аутистик спектры бозылган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программасы булу – 10 балл;<br>аутистик спектры бозылган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программасы булмау – 0 балл |
| Грант алырга теләүченең мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган уку-укыту программасында тәкъдим ителгән әлеге юнәлеш буенча эш формаларының, аутистик спектры бозылган балаларны укыту методикалары һәм технологияләренең төрлелеге һәм оригинальлеге | мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программасы буенча ике һәм аннан да күбрәк эш формасы булу, аутистик спектры бозылган балаларны укыту методикасы һәм технологияләре булу – 10 балл;<br>мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программасы буенча ике һәм аннан да күбрәк эш формасы булу, аутистик спектрында бозылышлары булган балаларны укыту методикасы һәм технологияләре булмау – 5 балл;<br>мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программасы буенча ике һәм аннан да күбрәк эш формасы булмау, аутистик спектры бозылган балаларны укыту методикасы һәм технологияләре булмау – 0 балл |

______________________________________